РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Сарлинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 68А, Азнакаевский
район, с.Сарлы, 423315,
тел./факс (885592)36-5-34
E-mail: Sarl.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 68 А йорт, Азнакай районы,
Сарлы авылы, 423315
тел./факс (885592)36-5-34
E-mail: Sarl.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «08» ноябрь, 2022 ел** **№6**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек авылында 2023 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын ТР, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Яшел ур., 34 адресы буенча урнашкан Сөендек авылы мәдәният йорты бинасында 2022 елның 23 ноябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 10 ноябреннән дә соңга калмыйча, гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Башкарма комитетында халык җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча тәэмин итәргә: Сарлы авылы, Үзәк урам, 68а йорт;
- сайлау хокукы булган Сөендек торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Сөендек торак пункты халкына халык җыены турында хәбәр итәргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2023 елда Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан,

Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 1500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 750 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәтенә түләү, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр сатып алу, янгын депосын агымдагы ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу);

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге (кардан чистарту);

- Бәйрәм чараларын оештыру өчен шартлар тудыру һәм бәйрәм чараларын уздыру ("Җиңү көне", "Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне", "Инвалидлар декадасы", "Яңа ел" бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу, милли бәйрәмнәр өчен реквизитлар алу (яңа ел чаналары, Сабантуй өчен арба), чараларны уздыру өчен аппаратура һәм инвентарь алу (4*8 м ябык павильон, рамлы түбә));

- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (Сөендек авылы мәдәният йорты өчен урам бәдрәфе сатып алу, чүплекләрне рекультивацияләү, Сөендек авылы Кооператив урамы буенча юл участогын ремонтлау, балалар өчен уен аттракционнары һәм спорт инвентаре сатып алу, үләнне механикалаштырылган чабу һәм триммер сатып алу, Сабантуй мәйданын төзекләндерү (капка, койма кую, сәхнә урнаштыру, багананы алыштыру, утыру урыннары ясау, бакча бәдрәфе сатып алу), МТЗ-82 өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (көрәк, сәнәк, КУН-10, щетка) һәм булган җиһазлар өчен (чапкыч, отвал) запас частьләре сатып алу, Сөендек авылы мәдәнят йортына кул насосы белән скважина урнаштыру, Сөендек авылында мәдәният йортын һәм башлангыч мәктәпне коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу);

- Сөендек авылы зиратларын карап тоту (8 куб. м ябык бункер алу, койма белән 3*4 контейнер мәйданчыклары урнаштыру, зиратларны чистарту)?

« РИЗА»  «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Сөендек авылы, Яшел урам, 34 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында,

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык  Л.М.Хаҗиев